# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Дәүләт гомуми белем учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем учреждениеләрендә укучыларга туклану өчен компенсация түләүләре турында

1 статья. Туклану өчен компенсация түләүләре - дәүләт гомуми белем учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем учреждениеләрендә укучыларга (әлеге учреждениеләрдә белем алучы тулысынча дәүләт тәэминатында торган укучылар моңа керми) туклануның кыйммәтләнүен өлешчә компенсацияләүгә бирелә торган түләүләр ул.

Туклану өчен компенсация түләүләре, уку елы дәвамында һәр укучы исәбеннән, чыгып законнар нигезендә билгеләнә.

2 статья. Әлеге Законны гамәлгә ашыруга бәйле финанс чыгымнары түбәндәгечә башкарыла:

- федераль законда билгеләнгән тәртиптә федераль бюджет акчалары исәбеннән;
- Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар исәбеннән финансланучы дәүләт гомуми белем учреждениеләрендә укучыларга көнгә Татарстан Республикасында билгеләнгән минималь эш хакының 1 проценты күләмендә, Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар исәбеннән финансланучы башлангыч һәм урта һөнәри белем учреждениеләрендә укучыларга көнгә Россия Федерациясендә билгеләнгән минималь эш хакының 3 проценты күләмендә, һәр укучыга - тиешле бюджет акчалары исәбеннән.

107



3 статья. Дәүләт гомуми белем учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем учреждениеләрендә укучыларга туклану өчен компенсация түләүләре тәртибе һәм шартлары, гаиләдә җан башына тигән уртача керемнән чыгып, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

4 статья. Әлеге Закон 1997 елның 1 гыйнвареннан көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1997 елның 12 феврале
N 1039